| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 сентября 2026 года № 307

Аксубаево

**"Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында 2027 елга өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында" 14.12.2009 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2027 елга:

"Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең норматив чыгымнарына 0,89 күләмендә төзәтү коэффициенты.

2. "Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең Финанс бюджет палатасы әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Бу карар рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2027 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Бу карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырылсын һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.09.2026 № 307
карары белән расланган

"Аксубай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | Дүрт еллык уку вакыты | Биш еллык уку вакыты | Җиде еллык уку вакыты | сигез еллык уку вакыты | иртә профессиональ ориентация |
| Музыка сәнгате | Шәһәр җирлеге | 105 697 | 101 123 | 102 469 | 118 007 | 122 699 | 159 744 |
| Музыка сәнгате | Авыл җирлеге | 110 117 | 105 355 | 106 758 | 122 939 | 124 998 | 166 404 |
| Рәсем сәнгате | Шәһәр җирлеге | | 52 845 | 44 975 | 41 603 | 45 921 | 105 191 |
| Музыка сәнгате | Авыл җирлеге | | 55 024 | 46 823 | 43 309 | 47 808 | 109 547 |
| Хореография сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 102 801 | 83 912 | 88 888 | 362 401 |
| Хореография сәнгате | Авыл җирлеге | | | 107 159 | 87 460 | 90 322 | 377 858 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 46 044 | | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 47 980 | | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 107 032 | 103 060 | 106 192 | 175 424 |
| Фольклор сәнгате | Авыл җирлеге | | | 111 545 | 107 405 | 108 259 | 182 820 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җирлеге | 165 636 | | 159 980 | | | 279 440 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җирлеге | 181 253 | | 166 727 | | | 291 215 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җирлеге | 82 098 | 74 124 | 76 772 | 76 747 | 80 358 | 114 174 |
| Театр сәнгате | Авыл җирлеге | 85 540 | 77 229 | 79 988 | 79 961 | 81 774 | 118 914 |